# ХӘЕРЛЕ ЮЛ

*сүзләре һәм көе – Шамил Сагаутдинов*

1. «Хәерле юл!» – ул электән килгән теләк.
   Юлчыларга бу сүз булган һәрчак терәк.
   Без дә сезнең юлыгызга уңыш юллыйк:
   Хәерле юл теләп калыйк.

   Хәерле юл сәфәр чыккан кешеләргә,
   Руль артында хезмәт иткән кардәшләргә,
   Биек күктә самолетта очканнарга,
   Диңгезләрне кичкәннәргә!

   **Кушымта:**

   Хәерле юл, хәерле юл тели сезгә ак каеннар!
   Хәерле юл, хәерле юл тели сезгә якын дуслар!
   Хәерле юл, хәерле юл – һәркемгә дә кирәк бит ул,
   Хәерле юл, хәерле юл!

2. Хәерле юл хезмәткәрләр-эшчеләргә,
   Мәктәпләргә аяк баскан балаларга,
   Никахланып тормыш корган бар яшьләргә,
   Тәпи баскан сабыйларга!

   Җиңел түгел тормышкайның зур юллары,
   Була алар сикәлтәле, борылмалы.
   Шулай да без, һич тә бирешми аларга,
   Җитик куйган максатларга!

   **Кушымта.**

**Счастливого пути**

Пожелание доброго пути водителям, летчикам, морякам и всем, кто в пути. А поскольку жизнь – это тоже путь, и самый большой путь, песня превращается в пожелание добра и счастья всем живущим на этой земле.